**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯЛАУР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Ялаур ав. КАРАР

«14» октябрь 2025 ел №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлегендә
Ялаур авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Ялаур җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 25 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Ялаур авылы, Үзәк урамы 25 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Үзәк урам буенча 1-85нче, Яшьләр урамы буенча 3-25нче, Пионер урамы буенча 2-5нче, Комсомол урамы буенча 5-23нче, Чапаев урамы буенча 1-22нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2025 елның 25 октябрендә 11 сәгать 00 минутка Ялаур авылы, Центральная урамы 25 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Ленин урамы буенча 1-69нчы, Калинин урамы буенча 1-68нче, Елга арьягы урамы буенча 4-14нче, Җиңүнең 40 еллыгы урамы буенча 2-10 нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гражданнар өчен тәэмин ителә.
4. Ялаур авылында яшәүчеләр җыенын уздыру өчен исемлекне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлегенең Ялаур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://pravo.tatarstan.ru Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур торак пунктындагы мәгълүмат стендларында, гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Ялаур авыл җирлеге башлыгы П.В.Сандиряков